КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 апрель г.Казань № 374

«Татарстан Республикасы кластерлы үсеше һәм проект идарәсе үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан кече һәм урта эшкуарлыкка, шулай ук «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» милли проект составына керүче федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашырылучы чараларны гамәлгә ашыру таләпләрен раслау турында» 2021 елның 26 мартындагы 142 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, «Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры» коммерциягә карамаган партнерлыгы» ассоциациясенең һәм «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыятенең «Татарстан Республикасы кластерлы үсеше һәм проект идарәсе үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасын (алга таба - Үзәк) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

Татарстан Республикасы исеменнән Үзәкне гамәлгә куючыларның берсе булырга;

30 көн эчендә башка гамәлгә куючылар белән берлектә Үзәк уставын расларга һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Үзәк идарәсе органнары составына Татарстан Республикасы вәкилләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен законнар нигезендә гамәлгә ашырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин